## КАРАР

“25” ноябрь 2022 ел № 13

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Сеҗе авыл җирлеге Починок Поник авылында халык җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1,56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2022 елның 25 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча үткәрелгән халык җыены нәтиҗәсе белән халык җыены беркетмәсе төзелде:

« Сез 2023 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Сеҗе авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 950 сум тәшкил иткән көндезге формада укучы студентлардан ,1нче группа инвалидлардан һәм 80 яшьтән узган гражданнардан тыш, 1900 сум күләмендә үзара салым кертү, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны (контракт буенча хәрби хезмәткәрләрне, мобилизацияләнгән, үз ихтыяры белән махсус хәрби операциядә катнашкан затларны) һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

- урамнарны яктырту челтәрләрен ремонтлау, шул исәптән яктырткычлар, лампалар, изоляцияләнгән чыбыклар, таймерлар, автоматлар, контакторлар сатып алу һәм урнаштыру;
- Кесмәс елгасы күпереннән башлап ком карьерындагы тауга кадәр юл полотносына нигез салу һәм вак таш җәю (3 этап);
- МТЗ 82.1 тракторына асылмалы җиһазлар сатып алуны финанслашу (үзбушаткыч тагылма);
- Лубай елгасы аша күпер төзү һәм материаллар сатып алу;

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә.

“ӘЙЕ” “КАРШЫ”

Халык җыены беркетмәсе (йомгаклау беркетмәсе) нигезендә сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 50 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 38 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучылар тавышы түбәндәгечә бүленде:

"Әйе" позициясе өчен халык җыенында катнашкан 36 кеше тавыш бирде;
“Каршы" позициясе өчен җыенда катнашкан 2 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Сеҗе авыл җирлегендә Починок Поник авылы халык җыенын узган һәм аның нәтиҗәләре дөрес дип танырга.

2.« Сез 2023 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Сеҗе авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 950 сум тәшкил иткән көндезге формада укучы студентлардан ,1нче группа инвалидлардан һәм 80 яшьтән узган гражданнардан тыш, 1900 сум күләмендә үзара салым кертү, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны (контракт буенча хәрби хезмәткәрләрне, мобилизацияләнгән, үз ихтыяры белән махсус хәрби операциядә катнашкан затларны) һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

- урамнарны яктырту челтәрләрен ремонтлау, шул исәптән яктырткычлар, лампалар, изоляцияләнгән чыбыклар, таймерлар, автоматлар, контакторлар сатып алу һәм урнаштыру;
- Кесмәс елгасы күперennнән башлап ком карьерындагы тауга кадәр юл полотносына нигез салу һәм вак таш җәю (3 этап);
- МТЗ 82.1 тракторына асылмалы җиһазлар сатып алуны финанслашу (үзбушаткыч тагылма);
- Лубай елгасы аша күпер төзү һәм материаллар сатып алу;

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә.

“ӘЙЕ” “КАРШЫ”

мәсьәләсе буенча карар кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны халык күп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларына ТР, Арча районы, Починок- Поник авылы, Ф.Бикбаев урамы, 15 нче йорт адресы буенча, интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм Татарстан

Республикасы Рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Сеже авыл җирлеге башлыгы
Р.В.Хәмидуллин